Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

13.04.2018 г.

КАРАР

№ 20

Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары

Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын җайга салу һәм иҗтимагый яктан гарантия белән тәэмин итү максатыннанТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Билгеләргә:

хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендәге аерым бюджет өлкәсе оешмаларыҗитәкчеләренең, белгечләр һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфа кеременнән, эшләнгән еллар өчен вазыйфа keremenә айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык вазыйфа керемeнә өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча бүләкләүдән, һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган түләүдән, матди ярдәм күрсәтүдән, һәм шулай ук закон нигезенә туры килә торган башка түләүләрдән тора. Белгечләр һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләү, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве

өчен һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкару керүне;

аерым оешма эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф бәясеннән, компенсация түләүләреннән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык тариф бәясенә өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча бүләкләүдән, һәр ел саен алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәмнән, машина йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмәдән, һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләүдән, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкарганга түләүдән, шулай ук закон нигезенә туры килә торган башка түләүләрдән торуны;

аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең, хезмәткәрләренең вазыйфа кереме күләме аерым оешма җитәкчеләренең сәркатипләренеке белән бермәбер күләмдә, 11 163, 0 сумны тәшкил итүне;

аерым оешма эшчеләренең айлык тариф бәясе һәм компенсацион түләү күләме Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл жирлеге бюджетыннан финанслана торган бюджет өлкәсенә караучы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы бәяләнә торган Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнүне.

2. Расларга:

аерым оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфа кеременең күләмен исәпләү өчен кулланыла торган бермәбер коэффициентын, 1нче кушымта нигезендә;

хезмәткәрләрнең вазыйфа кеременең күләмен исәпләгәндә кулланыла торган бермәбер коэффициентын, 2нче кушымта нигезендә;

аерым оешмаларда хезмәт күрсәтүче эшчеләрнең хезмәт хакын түләгәндә кулланыла торган дәрәҗә диапозонын, 3нче кушымта нигезендә.

3. Аерым оешма җитәкчеләренә, белгечләренә, хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) эшләнгән еллар өчен вазыйфа keремeнә айлык өстәмә түбәндәге күләмедә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентта |
|---|---|
| 1 - 5 ел | 5 |
| 5 -10 ел | 7 |
| 10 - 15 ел | 10 |
| 15 елдан югары | 15 |

2) катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык вазыйфа керемeнә өстәмәнең күләмен вазыйфа керемeнең 10 % итеп;

3) айлык акчалата бүләкләүне вазыйфа керемeнең 2 % күләмендә;

4) эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында (бүләкләүнең күләме хезмәткәрнең эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә һәм зур күләм белән чикләнми);

5) һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган түләү вазыйфа керемeннең 120 % күләмендә;

Җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә түләүле ял күрсәтелсә, бер тапкыр бирелә торган өстәмә эшләгән вакыт дәверенә пропарциональ рәвештә декабрь аенда түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көнендә.

Еллык түләүле ял вакытында бер тапкыр бирелә торган түләү җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә беренче эш елында эшләгән вакыт дәверенә карап түләнә. Эшләгән вакыт дәвере эшкә кергән көннән алып шул елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

6) матди ярдәм, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләү, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкарганга түләү вазыйфа керемeнең 50 % кадәр билгеләргә, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында.

5. Аерым оешма эшчеләренә билгеләргә:

1) катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык тариф бәясенә өстәмәнең күләмен айлык тариф бәясенең 50 % кадәр, җиңел машина йөртүчеләрнең нормага салынмаган эш көне өстәмәсен исәпкә алмыйча;

2) эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү (бүләкләүнең күләме хезмәткәрнең эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә һәм зур күләм белән чикләнми);

3) һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәмнең күләме ике айлык тариф бәясе, 25 % айлык тариф бәясеннән бүләкләүне исәпкә алып.

Әгәр дә эшчегә еллык түләүле ял күрсәтелмәсә, һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәм эшләгән вакыт дәверенә пропарциональ рәвештә декабрь аенда исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көнендә.

Һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәм беренче эш елында эшләгән вакыт дәверенә пропарциональ рәвештә түләнә. Эшләгән вакыт дәвере эшкә кергән көннән алып шул елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

4) матди ярдәм, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында;

5) эш урынының җиңел машинасын йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмә түбәндәге күләмдә:

I класслы машина йөртүчеләр – билгеләнгән айлык тариф бәясенең 25 %, машина йөртүче булып эшдәгән дәвер өчен;

II класслы машина йөртүчеләр – билгеләнгән айлык тариф бәясенең 10 %, машина йөртүче булып эшдәгән дәвер өчен;

6) айлык өстәмә:

һөнәрләрне берләштерү өчен өстәмә түләү, хезмәт күрсәтү өлкәсенең киңәеве һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча килми калган хезмәткәрнең эшен башкарганга түләү – айлык тариф бәясенең 50 % кадәр, төп эш урыны буенча гамәлдәге законда билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында;

төнге сәгатьләрдә эшләгәнгә (22:00-06:00 сәг.) – сәгатьле тариф бәясенең 35 % күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгәнгә – икеләтә көнлек тариф бәясе күләмендә;

эш урынының җиңел машинасын йөртүчеләргә нормага салынмаган эш көне өчен – айлык тариф бәясенең 50 % кадәр булган күләмдә.

6. Эшчеләргә Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә каралган башка түләүләр булдырырга.

7. Аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондын оештырганда вазыйфа керемен түләргә юнәлтелгән чаралар суммасыннан тыш карала торган түбәндәге түләүләрне билгеләргә (12 вазыйфа кеременнән чыгып еллыкка исәпләнә):

1) эшләнгән еллар өчен айлык өстәмә – вазыйфа кеременең 7 % күләмендә;

2) катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык вазыйфа керемен өстәмә - вазыйфа кеременең 10 % күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү - вазыйфа кеременең 1 % күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфа кеременең 2 % күләмендә;

5) һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган түләү һәм матди ярдәм вазыйфа кеременеә 10 % күләмендә.

8. Аерым оешма эшчеләренең хезмәт хакы фондын оештырганда тариф бәясен (компенсацион түләүләрне исәпкә алып) түләргә юнәлтелгән чаралар суммасыннан тыш карала торган түбәндәге түләүләрне билгеләргә (еллыкка исәпләгәнә):

1) катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык тариф бәясенә өстәмәнең күләме – 1 айлык тариф бәясе күләмендә;

2) җиңел машинайөртүчеләргә класс өчен, нормага салынмаган эш көне өчен айлык өстәмә–9 айлык тариф бәясе күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча бүләкләү – 3 айлык тариф бәясе күләмендә;

4) һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган матди ярдәм – 2 айлык тариф бәясе күләмендә, айлык тариф бәясенең 25 % күләмендәге бүләкләүне исәпкә алып.

9. Билгеләргә:

аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфа кереме күләме, шулай ук аерым оешма эшчеләренең айлык һәм башка түләүләр күләме арттыру ягына таба суммның бөтен өлешенә түгәрәкләүне;

аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфа керемен арттыру билгеле бер күләмдә һәм вакытта үткәрүне,

ТатарстанРеспубликасы Сабв муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендәге хезмәткәрләрнең вазыйфа керемен арттыру очрагы каралганда;

аерым оешма эшчеләренә әлеге карар кабул ителгәннән соң хезмәт хакы түләү буенча булган башка шартлар кулланылмый.

10. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып 10 көн узганнан соң үз көченә керә, 1 апрель 2018 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Загидуллин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.04.2018 №20 карарына кушымта №1

Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендәге аерым бюджет өлкәсе оешмаларыҗитәкчеләренең, белгечләренең вазыйфа керемен исәпләгәндә кулланыла торган бермәберлек коэффициенты

| Вазыйфа атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә итү җитәкчесе (структур бүлекчәләренең, бүлекләрнең) | 1,34 |
| Мөстәкыйль идарә итү җитәкчесе урынбасары(структур бүлекчәләренең, бүлекләрнең) | 1,30 |
| Бүлек башлыгы | 1,25 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,17 |
| Баш белгеч | 1,10 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,05 |
| Ікатегорияле белгеч | 1,00 |
| II категорияле белгеч | 1,00 |
| Белгеч | 1,00 |

Татарстан Республикасы Сабамуниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.04.2018 №20 карарына кушымта №2

Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендәге аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфа керемен исәпләгәндә кулланыла торган бермәберлек коэффициенты

| Вазыйфа атамасы | Коэффициент |
| --- | --- |
| Архив мөдире, өлкән инспектор, инспектор, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, делопроизводитель, архивариус, стенографистка, сәркатип-стенографистка, машинистка, сәркатип-машинистка, җитәкче сәркатибе | 1,0 |

Татарстан Республикасы Сабамуниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.04.2018 №20 карарына кушымта №3

Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендәге аерым бюджет өлкәсе оешмаларында хезмәт күрсәтүче эшчеләрнең хезмәт хакын түләгәндә кулланыла торган дәрәҗә диапозоны

| Һөнәр атамасы | Хезмәт хакы дәрәҗәсе |
|---|---|
| Гардеробщик, урам себерүче, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), җитештерү һәм хезмәт күрсәтү биналарын җыештыручы, лифтер, кладовщик, йөкче | 1 – 2 |
| Электрон-исәпләүһәмисәпләүмашиналары операторы,биналар буенча комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшчесе | 2 – 4 |
| Копия ясый һәм чыгара торган машиналар операторы | 2 – 3 |
| Җиңел машина йөртүчесе | 4 – 5 |

Искәрмә:

Җитештерү һәм хезмәт күрсәтү биналарын җыештыручыга тариф бәясенең икенче дәрәҗәсе җитештерү биналары бергә җитештерү калдыкларын, юыну бүлмәләрен һәм җәмәгать бәдрәфләренҗыештырганда куела.

Машина йөртүчеләргә тариф бәясенең бишенче дәрәҗәсе 2-3 төрдәге машинада эшләгәнгә, шулай ук махсус техник хезмәт күрсәтү машиналары булмаган очракта комплекслы ремонт һәм хезмәт күрсәтү машиналарында эшләгән очракта гына куела.